**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Шәһәр тибындагы**
**Аксубай поселогы**
**Башкарма комитеты**
**423060, Аксубай эшчеләр поселогы,**
**Советлар урамы, 2 нче йорт**
**т.2-73-62**

**Исполнительный комитет**
**поселка городского типа Аксубаево**
**Аксубаевского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**423060, р.п. Аксубаево,**
**ул.Советская, д.2**
**т. 2-73-62**

---

КАРАР

№ 7 17.03.2016 ел.

Халыкка мунча хезмәте күрсәтүче оешмаларның керемнәрен каплауга субсидияләр исәпләү һәм бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына ярашлы рәвештә , муниципаль берәмлек депутатлары Советының 2016 елга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының « Аксубай шәһәр тибындагы поселогы » муниципаль берәмлеге бюджеты турында 18.12.2015 ел, № 13 карары белән :

1.Халыкның ташламалы категориясе ( пенсионерлар , инвалидлар) өчен халыкка мунча хезмәте күрсәтүче оешмаларның керемнәрен каплауга субсидияләр бирү тәртибе һәм субсидияләр бирү турында нигезләмәне расларга ( 1 нче кушымта).

2.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам .

Аксубай муниципаль районы

шт Аксубай бистәсе башкарма комитеты җитәкчесе В.В. Кононов

Аксубай муниципаль районы
шт Аксубай бистәсе башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта

Халыкның ташламалы категориясе (пенсионерлар, инвалидлар) өчен халыкка мунча хезмәте күрсәтүче оешманың керемнәрен каплауга субсидияләр бирү һәм исәпләү тәртибе турында нигезләмә

Гомуми нигезләмә

1.1. Халыкның ташламалы категориясе ( пенсионерлар , инвалидлар )өчен мунча хезмәтләре күрсәтүче оешманың һәм халыкка төшүче керемнәрне каплауга исәп-хисап һәм субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмә

1.2.Положениедә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла :

Субсидияләр-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының « Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан үзкыйммәтеннән түбән бәяләр буенча мунча хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән оешма чыгымнарын каплауга бүлеп бирелә торган акчалар ;

Субсидия алучы-Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты белән халыкның ташламалы категориясе ( пенсионерлар , инвалидлар)өчен халыкка мунча хезмәтләре күрсәтү чыгымнарын каплау өчен субсидия алу турында килешү төзегән оешма;

Фиксацияләнгән Тарифлар буенча мунча хезмәтләре Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 02.03.2016 елның 89 номерлы карары белән расланган тарифлар буенча оешма тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләре ;

Ташламалы категорияле халыкка мунча хезмәтләре күрсәтү белән бәйле чыгымнар ташламалы категорияле халыкка билетлар сатудан оешмада барлыкка килгән чыгымнар

(пенсионерлар, инвалидлар), ташламалы билет бәясе 2016 елның гыйнварында 1 кеше өчен 60 сум тәшкил итә, 2016 елның 1 февраленнән 1 кеше өчен 80 сум.

1.3.Субсидияләр халыкның ташламалы категориясенә мунча хезмәтләре күрсәтүдән барлыкка килгән зыянны каплау өчен оешмаларга бирелә.

1. Субсидияләр күләмен исәпләү тәртибе

2.1.Субсидияләр күләме халыкның мунча хезмәтләренә расланган тарифлар һәм халыкның ташламалы категориясендәге (пенсионерларга, инвалидларга)күрсәтелгән хезмәтләр чыгымнары арасындагы аерма буларак исәпләнә

2. Субсидияләр бирү тәртибе

3.1.Субсидияләр алучы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетына отчет аенда хезмәт күрсәтүгә бәйле югалтулар турында хисап( 1 нче кушымта) бирә.

3.2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты бирелгән документлар белән исәп-хисапны тикшерә ( Керем –касса ордерлары , югалтулар турында хисап - килешүгә 1 нче кушымта , күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итүне тапшыру акты-килешүгә 2 нче кушымта , халыкның ташламалы категориясе билетларының күчермәләре )., мунча хезмәтләре күрсәтү белән бәйле һәм әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә субсидия күләмен исәпли.

3.3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының « Аксубай шәһәр тибындагы поселогы « муниципаль берәмлеге бюджетында каралган акчалар чикләрендә « коммуналь хуҗалык өлкәсендә чаралар»максатчан статьясы буенча исәп-хисап счетына субсидияләр алучыга күчерүне гамәлгә ашыра

3.4 субсидияләрне максатсыз куллану билгеләнгән очракта, аларның күләме максатсыз куллану суммасына кими. Субсидияләрне максатсыз куллануда гаепле булган субсидияләр алучы оешманың җитәкчесе гамәлдәге закон нигезендә җаваплы.